КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 849

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы; 2016 ел, 7 октябрь, 720 нче; 2017 ел, 25 май, 299 нчы; 2020 ел, 18 июль, 605 нче; 2021 ел, 31 май, 424 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1044 нче; 2023 ел, 1 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга;

1.7 пунктта:

җиденче абзацта «10» саннарын «биш» сүзенә алмаштырырга;

уникенче абзацта «биш берәмлеккә» сүзләрен «өч берәмлеккә» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «өч берәмлеккә» сүзләрен «бер берәмлеккә» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «бүтән республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның 3 пунктындагы беренче графасында «10 процент» сүзләрен «20 процент» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтаның 2 пунктындагы икенче абзацында «10 процентка» сүзләрен «5 процентка» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин